**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**МЮД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

№ 9 14 .11.2020 ел

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Мюд авыл җирлеге Советының
«Җир салымы турында» 05.11.2019 ел, №100
карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында» 29.09.2019 ел, №325-ФЗ Федераль законга, 01.01.2021 елның үз көченә керәторган һәм муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары вәкаләтләреннән салым түләүчеләр өчен җир салымы буенча салым һәм аванс түләүләрен түләү срокларын билгеләү хокукын төшереп калдыручы Россия Федерациясе Салым кодексының 387 статьясындагы 2 пунктының беренче абзацына үзгәрешләр кертү белән бәйле рәвештә,Татарстан Республикасы Аксубай районы Прокуратурасы мәгълүматын игътибарга алып һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел,№131-ФЗ Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Мюд авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 05.11.2019 ел, №100 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. «Салым түләү тәртибе һәм сроклары» 5 статьясын төшереп калдырырга.
2. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.
3. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга: http://aksubayevo.tatar.ru һәм хокукый мәгълүмат порталында бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru/.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Аксубай муниципаль районы
Мюд авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе Т.В. Зюзина